**КАРАР**
**Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы**
**Актүбә шәһәр тибындагы бистә Советы**

Актүбә ш.т.б. № 51 «16» декабрь 2019 ел

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Актүбә шәһәр тибындагы поселогы Советының 2016 елның 09 сентябрендәге 13 нче номерлы карары белән расланган, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының «Актүбә шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлегенең муниципаль милкен хосусыйлаштыру тәртибе турындагы Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында (11.11.2016 № 18, 25.09.2017 № 21, 15.02.2018 № 4 карарлар редакциясендә)

РФ Хөкүмәтенең «Урман фонды җирләрендә урнашкан урманнардан файдаланганда киселгән агачны сату кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында» 2009 елныц 17 октябрендәге 1341 нче номерлы карары, Россия Федерациясе Урман кодексының 43-46 статьялары һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларының һәм аерым нигезләмәләренең үз көчләрен югалтуын тану турында Нигезләмә һәм дәүләт яисә муниципаль милекне электрон формада сатуны оештыру һәм үткәрү турында Нигезләмә нигезендә, 2019 елның 8 ноябрендәге 02-08-02/1397-2019 номерлы Азнакай шәһәр прокуроры протестын исәпкә алып

**Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы**
**Актүбә шәһәр тибындагы бистә Советы карар нтте:**

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Актүбә шәһәр тибындагы поселогы Советының 2016 елның 09 сентябрендәге 13 нче номерлы карары белән расланган, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының «Актүбә шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлегенең муниципаль милкен хосусыйлаштыру тәртибе турындагы Нигезләмәгә (11.11.2016 № 18, 25.09.2017 № 21, 15.02.2018 № 4 карарлар редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 2.1, 2.23, 3.1 пунктларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының «Актүбә шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге җирле үзидарә органнары мөстәкыйль рәвештә мөлкәт сату функцияләрен гамәлгә ашыралар, шулай ук үз карарлары белән «Дәүләт һәм муниципаль милекне хосусыйлаштыру турында» 21.12.2001 елның 21 декабрендәге 178-ФЗ номерлы Федераль законның 6

статьясындагы 1 пунктының 8.1 пунктчасында күрсәтелгән юридик затларга, милекче исеменнән билгеләнгән тәртиптә хосусыйлаштырыла торган мөлкәтне сатуны оештырырга һәм (яки) мөлкәт сатучы функцияләрен гамәлгә ашырырга кушалар.».

1.2. 6 бүлектәге 3.2 пунктының «н» пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«н) җиңүче белән электрон документ формасында сату-алу килешүе төзи;».

2. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында» түбәндәге веб-адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге адрес буенча урнаштырырга: http://aznakayevo.tatar.ru..

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Актүбә шәһәр тибындагы бистәсе Советының законлылык, хокук тәртибе, депутат этикасы һәм җирле үзидарә мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Рәис Р.А. Галеева